КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 5 апрель г.Казань № 207

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2017 ел, 18 сентябрь, 699 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2017 ел, 18 сентябрь, 699 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган дәүләт хезмәте күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентларының 5.17 пункты үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрына кертелгән, әмма социаль хезмәтләр күрсәтү белән бәйле дәүләт заказын үтәүдә катнашмаучы дәүләтнеке булмаган оешмаларга компенсация түләүгә (чыгмнарны каплауга) Татарстан Республикасын бюджетында күздә тотылган акча күләмен билгеләү өчен кеше, койка-көн санын яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән).

2. Бу караның гамәле 2018 елның 1 гыйнварынна барлыкка килгә хокук мөнәсәбәтләренә тарала дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин